СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.07.2015 г.Агрыз № 42-5

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2014 елның 13 октябрендәге 35-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы " Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы һәм структур үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2014 елның 13 октябрендәге 35-1 номерлы «Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының торышы һәм структурасы турында» гы карарының 1 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 нче кушымтаны (Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы структурасын) яңа редакциядә бәян итәргә (1 нче кушымта)

2.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы:

- 2015 елга расланган Бюджет кысаларында Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасын финанслауны гамәлгә ашырырга;;

- алдагы елларга бюджет формалаштырганда әлеге карарны исәпкә алырга.

3. Әлеге карарны http://agryz.tatarstan.ru Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының Законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча Даими комитетына (И.М. Карамиев) йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы В. В. МАКАРОВ

СОВЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Общий отдел
Гомуми бүлек

Әгерҗе муниципаль районы Советы 2015 елның 22 июле, № 42-5Карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районының
Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы структурасы

| №<br>№ | вазыйфасы атамасы | берәмлекләр саны |
|---|---|---|
| **Җитәкчелек** | | |
| 1 | Җитәкче | 1 |
| 2 | Җитәкче урынбасары | 1 |
| **Контроль һәм исәп бүлеге** | | |
| 3 | Бүлек начальнигы | 1 |
| 4 | Главный специалист | 1 |
| | **Барлыгы:** | **4** |